КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1111

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаган затларга мөнәсәбәттә опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча бирелгән вәкаләтләрне тормышка ашыру тәртибен раслау турында» 2008 ел, 1 декабрь, 843 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында балигъ булмаган затларга мөнәсәбәттә опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча бирелгән вәкаләтләрне тормышка ашыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаган затларга мөнәсәбәттә опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча бирелгән вәкаләтләрне тормышка ашыру тәртибен раслау турында» 2008 ел, 1 декабрь, 843 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында балигъ булмаган затларга мөнәсәбәттә опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча бирелгән вәкаләтләрне тормышка ашыру тәртибенә, «Россия Федерациясендә Мәгариф хакында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның «Мәгариф буенча белгечлекләрнең бөтенроссия классификаторын кабул итү һәм куллануга кертү турында (ОКСО) ОК 009-2016» 2016 ел, 8 декабрь, 2007-ст боерыгы һәм Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексының 8 статьясындагы 4 пункт нигезендә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Җирле үзидарә органы җитәкчесе, бала хокукларын саклау буенча белгеч Татарстан Республикасында балигъ булмаган затларга мөнәсәбәттә опека һәм попечительлек буенча дәүләт вәкаләтләрен башкарганда үз эшчәнлегендә түбәндәгеләргә таянып эш итә:

Россия Федерациясе Конституциясе;

«Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны социаль яклау буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Балигъ булмаганнарның күзәтүсезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауның төп системалары турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар турында мәгълүматларның дәүләт банкы хакында» 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә Мәгариф турында»; 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Граждан кодексы;

Россия Федерациясе Гаилә кодексы;

Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның «Мәгариф буенча белгечлекләрнең бөтенроссия классификаторын кабул итү һәм куллануга кертү турында (ОКСО) ОК 009-2016» 2016 ел, 8 декабрь, 2007-ст боерыгы;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән законнары һәм норматив хокукый актлары.»;

1.6 пунктта «югары педагогик яки юридик белеме һәм алынган белгечлеге буенча кимендә 3 ел эш стажы булган» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимият органы раслаган вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәр һәм опека һәм попечительлек органнары хезмәткәрләре күнекмәләре таләпләренә туры килә торган.» сүзләренә алмаштырырга;

1.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.10. Бала хокукларын саклау буенча белгеч башкарма хакимият, җирле үзидарә органнары һәм федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, белем бирү оешмалары, медицина оешмалары, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалар яки бүтән, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмалар, иҗтимагый оешмалар вәкилләре белән үзара бәйләнештә була.»;

2.6 пунктта «учреждение» сүзен «оешма» сүзенә алмаштырырга;

2.10 пунктта «мәгариф, сәламәтлек саклау һәм халыкны социаль яклау учреждениеләрендә» сүзләрен «белем бирү оешмаларында, сәламәтлек саклау оешмаларында һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

2.14 пунктның унберенче абзацында «дәүләт учреждениесе» сүзләрен «дәүләт оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктта «учреждениеләр,» сүзен төшереп калдырырга;

3.2 пунктта «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин